СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2026 елның 29 мае № 9/12

Пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү турында

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләр тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (11.05.2018 № 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1, 10.11.2022 № 22/3, 14.12.2022 № 23/9, 13.02.2023 № 25/3, 29.05.2024 № 38/6, 08.11.2024 № 40/6, 22.05.2025 № 46/2, 15.12.2025 № 4/5 редакциясендә) «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»гы карары белән расланган пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү тәртибенең **2 пунктына** һәм түләү шартларына, түбәндәге эчтәлекле **абзац өстәп**, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль вазыйфаны биләүче затны бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата бүләкләү суммасына түбәндәгеләр керә: айлык акчалата бүләкләү һәм айлык акчалата түләү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районын рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров